РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КОШКИ-ТЕНЯКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КҮШКЕ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«29» апрель 2025 ел №15

Буа муниципаль районы Күшке авыл җирлегенең муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 509-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә Буа муниципаль районы Күшке авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Буа муниципаль районы Күшке авыл җирлеге Башкарма комитетының «Буа муниципаль районы Күшке авыл җирлеге муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2016 елның 13 декабрендәге 13 номерлы карары белән расланган Буа муниципаль районы Күшке авыл җирлегенең муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә ( 15.06.2020 №6, от 26.05.2021 №12, 25.03.2022 №12 карары редакциясендә) (алга таба-Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 2 бүлек

2.2 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары, аларны башкару тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре. Бүлектә дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү вариантлары булырга тиеш, аларда гомуми билгеләр белән берләштерелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә, шул исәптән алар сорап мөрәҗәгать иткән дәүләт яки муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә карата да, күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү тәртибе кертелергә тиеш.».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы Күшке

авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе А.В. Стрелков